ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР** 14.12.2023 2021 **КАРАР**

2023-2025 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында

Россия Федерациясе Торак Кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законын үтәү йөзеннән, Алабуга муниципаль районында торак фондын саклап калу һәм торгызу максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023-2025 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын расларга.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2023 елның 13 октябрендәге 1595 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.12.2023 2021
карарына 1 нче кушымта

**2023-2025 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

2023-2025 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы (алга таба - Кыска сроклы план, региональ программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Тораккоммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы), күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләрен аныклау, дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү, капиталь ремонт үткәрүгә муниципаль ярдәм күрсәтү күләмен билгеләү максатларында эшләнде.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары түбәндәгеләр:

– Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын яхшырту;

– гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру;

- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары түбәндәгеләр:

– халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

– кыска сроклы планны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;

- озак саклана торган материаллар һәм ресурслар саклый торган технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләр һәм комплекслылык куллану.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру срогы: 2023-2025 еллар.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыруның гомуми мәйданы 367,531 мең кв. метр булган 64 күпфатирлы йортларда 13 852 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итү.

Әлеге кыска сроклы планны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре тулаем Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы буенча кыска сроклы планга 1 нче кушымтада бирелгән.

## III. 2023 елда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау күләмнәре

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Түбәне ремонтлау | мең кв. метр | 3,58 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, төзекләндерү эшләре, шул исәптән: | мең метр | 91,9 |
| Электр белән тәэмин итү | мең метр | 17,65 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 19,94 |
| Салкын су белән тәэмин итү | мең метр | 11,44 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | мең метр | 10,92 |
| Ташландык суларны чыгару | мең метр | 15,14 |
| Газ белән тәэмин итү | мең метр | 16,81 |
| Лифт шахталарын төзекләндерү, ремонтлау өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын төзекләндерү һәм алыштыру | данә | 11 |
| Фасадны ремонтлау/җылыту | мең кв.метр | 17,98 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 20 |

## 2024 елда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау күләмнәре

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Түбәне ремонтлау | мең кв. метр | 5,04 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, төзекләндерү эшләре, шул исәптән: | мең метр | 113,36 |
| Электр белән тәэмин итү | мең метр | 0 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 22,87 |
| Салкын су белән тәэмин итү | мең метр | 23,26 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | мең метр | 22,87 |
| Ташландык суларны чыгару | мең метр | 23,26 |
| Газ белән тәэмин итү | | 21,1 |

| | | |
|---|---|---|
| Лифт шахталарын төзекләндерү, ремонтлау өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын төзекләндерү һәм алыштыру | данә | 10 |
| Фасадны ремонтлау/җылыту | мең кв. метр | 23,08 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 21 |

**2025 елда күпфатирлы йортларга капиталь гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау күләмнәре**

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Түбәне ремонтлау | мең кв. метр | 6,1 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, төзекләндерү эшләре, шул исәптән: | мең метр | 73,17 |
| Электр белән тәэмин итү | мең метр | 2,88 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 22,16 |
| Салкын су белән тәэмин итү | мең метр | 17,59 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | мең метр | 3,63 |
| Ташландык суларны чыгару | мең метр | 26,91 |
| Лифт шахталарын төзекләндерү, ремонтлау өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын төзекләндерү һәм алыштыру | данә | 8 |
| Фасадны ремонтлау/җылыту | мең кв. метр | 16,23 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 23 |

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре һәм 2023-2025 елларга капиталь ремонт үткәрү срогы, бәясе, күпфатирлы йортлар исемлеге күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча кыска сроклы планга 2 нче кушымтада китерелгән.

## IV. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска сроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты акчалары, торак милекчеләре ширкәтләре әгъзалары, торак, торак-төзелеш кооперативлары (алга таба - ТМШ, ТК, ТТК) яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары йә күпфатирлы йорттагы торак милекчеләре тора. Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 431 164 578,88 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән чаралар:

Татарстан республикасы бюджеты-82 465 121,59 сум;

Алабуга муниципаль районы бюджеты - 98 772 573,68 сум;

Торак милекчеләре ширкәте, торак-коммуналь хуҗалык, (ТТК), башка кулланучылар кооперативлары яки күп фатирлы йортларда биналарның милекчеләре- 249 926 883,61 сум.

**2023 елда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясауга финанс чаралары күләме.**

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, млн. сум |
|---|---|
| Түбәне ремонтлау | 13,7 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, төзекләндерү эшләре, шул исәптән: | 25,805 |
| Электр белән тәэмин итү | 2,55 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 6,085 |
| Салкын су белән тәэмин итү | 1,58 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | 0,95 |
| Ташландык суларны чыгару | 5,9 |
| Газ белән тәэмин итү | 1,93 |
| Лифт шахталарын төзекләндерү, ремонтлау өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын төзекләндерү һәм алыштыру | 27,5 |
| Фасадны ремонтлау/җылыту | 71,99 |
| Проект-смета документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 4,87 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 2,27 |
| Барлыгы | 153,44 |

**2024 елда күпфатирлы йортлардагомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясауга финанс чаралары күләме**

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, млн. сум |
|---|---|
| Түбәне ремонтлау | 21,33 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын, шул исәптән: | 24,805 |
| Электр белән тәэмин итү | 0 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 13,2 |
| Салкын су белән тәэмин итү | 3,4 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | 3,27 |
| Ташландык суларны чыгару | 5,808 |
| Газ белән тәэмин итү | 1,55 |
| Лифт шахталарын төзекләндерү һәмтөзекләндерү өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын төзекләндерү яки алыштыру | 35 |

| | |
|---|---|
| Фасадны төзекләндерү/җылыту | 61,5 |
| Проект-смета документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 5,23 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 2,205 |
| Барлыгы | 158,523 |

**2025 елда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясауга финанс чаралары күләме.**

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, млн. сум |
|---|---|
| Түбәне ремонтлау | 17,75 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын, шул исәптән: | 26,44 |
| Электр белән тәэмин итү | 1,4 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 9,2 |
| Салкын су белән тәэмин итү | 2,3 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | 1,597 |
| Ташландык суларны чыгару | 3,8 |
| Лифт шахталарын төзекләндерү һәмтөзекләндерү өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын төзекләндерү яки алыштыру | 21 |
| Фасадны төзекләндерү/җылыту | 50,31 |
| проект-смета документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 4,161 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 1,725 |
| Барлыгы | 119,201 |

2023-2025 елларда капиталь ремонт үткәрүнең бәясе йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча кыска сроклы планга 3 нче кушымтада китерелгән.

**V. Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе.**

2023-2025 елларга күпфатирлы йортлардагы гомуми мәйданның 1 кв. метрына исәпләгәндә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе 9 мең сум тәшкил итә. Шул ук вакытта күпфатирлы йортларга капиталь ремонт буенча әлеге кыска сроклы планга кертелгән хезмәтләрнең (эшләрнең) иң чик хакы күләме эш төрләре буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба - Министрлык) боерыгы белән раслана.

Капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик хакын арттыру, шулай ук кыска сроклы планда каралмаган хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертем рәвешендә капиталь ремонт өчен минималь кертем

күләменнән артык түләнә торган акчалары хисабына тормышка ашырыла. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыруга каралган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) капиталь ремонт буенча эшләрнең иң чик хакын арттыруны җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләргә мөмкин..

## VI. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге кыска сроклы планны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, ТМШ, ТК, ТТК, идарәче оешмалар (алга таба - ИО), торак милекчеләре, подряд оешмалары (алга таба - Кыска вакытлы планны үтәүчеләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты:

Министрлыкка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, Төбәк программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын төзи һәм җибәрә;

Министрлыкка норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне раслый торган башка документларны тапшыра;

җирле бюджет акчаларын торак законнары нигезендә кыска сроклы план белән билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга күчерә;

региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләренә техник заказчы функцияләрен гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт буенча эшләр башкару актларын, күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау чыгымнарының расланган сметасында каралмаган акчалардан файдалану очракларыннан тыш, шулай ук арттырылган очракта, килештерә;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау эшләрен уздыруга бүлеп бирелә торган акчалардан максатчан файдалануны тикшереп тора;

тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру максатларында белешмәләр базасын (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган биналар мәйданнары буенча белешмәләр) төзи һәм аны актуаль халәттә тота;

Министрлыкка һәм Кыска сроклы планны башка башкаручыларга дәүләт корпорациясенә - Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды хисапларын формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыра.

ТМШ, ТТК, ТК, ИО:

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефектлы ведомостьларны килештерәләр;

проект документациясен килештерүне тәэмин итәләр;

торак милекчеләренә капиталь ремонт башлану срогы, хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тапшыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышларын оештыралар;

капиталь ремонт объектларына кертүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауны үз вакытында һәм сыйфатлы үтәүне тикшереп торалар, шулай ук тикшерү актларына имза кую хокукы белән капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә һәм тәмамланган капиталь ремонт объектларын файдалануга тапшыру актларында катнашалар;

күпфатирлы йортны авариясез эксплуатацияләүнең һәм аңа керүче инженерлык системаларының билгеләнгән гарантия срогыннан да ким булмаган күләмдә күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау буенча дефектлы ведомостьлар, проект-смета һәм башкарма документацияне саклыйлар;

ТМШ, ТТК, ТК, ИО түләү документлары төзи һәм төбәк операторы исәбенә капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча түләүләрне, шулай ук капиталь ремонт һәм пеня өчен кертемнәрне түләү буенча бурычларны түләтү буенча төбәк операторы белән килешүләр (шартнамәләр) төзиләр.

Торак милекчеләре:

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефектлы ведомостьларны килештерәләр;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауны үз вакытында һәм сыйфатлы үтәүне контрольдә тотуда, шулай ук аларны тикшерү актларының һәм тәмамланган капиталь ремонт объектларын файдалануга тапшыру актларының имзасы хокукы белән файдалануга тапшыруда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен кыска срокларда һәм подряд шартнамәсендә билгеләнгән срокларда башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формалары буенча башкарылган эшләр актларын төзиләр;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау эшләрен сыйфатлы һәм вакытында үтәгән өчен җаваплы булалар;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд шартнамәсендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешмалар:

Техник заказчылар:

проект документациясен, шул исәптән сметасын әзерли һәм раслый;
күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләр кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны кабул итүдә катнашалар, капиталь ремонт эшләрен кабул итү буенча комиссияләр төзиләр, күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау эшләрен кабул итү буенча комиссия актларын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау эшләрен сыйфатлы һәм вакытында үтәгән өчен җаваплы булалар;

проект оешмасыннан проект документациясен кабул итәләр;

күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яисә) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча башкарылган эшләр актына кул кую датасыннан 10 көн эчендә күпфатирлы йортта шуны күпфатирлы йорт белән идар

Документ создан в электронной форме. № 2021 от 14.12.2023. Исполнитель: Мусина Е.А.
Страница 8 из 11. Страница создана: 14.12.2023 13:22

гамәлгә ашыручы затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән капиталь ремонт буенча эшләр башкару турында проект-смета документларының, хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр башкару турындагы шартнамәләрнең күчермәләрен) һәм, финанс документларыннан тыш, капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документларны тапшыралар.

2019 елның 1 гыйнварыннан мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә шәһәр җәмәгатьчелеге - «Новая Кама» шәһәр иҗтимагый-сәяси газетасы, «Алмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы массакүләм мәгълүмат чараларында Кыска сроклы план чараларын гамәлгә ашыру барышын даими яктыртып бара.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## VII. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкару өчен подряд оешмаларын сайлап алу тәртибе.

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә хезмәт күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен подрядчы оешмаларны җәлеп итү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 1 июлендәге 615 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә региональ оператор тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2023-2025 елларда Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына 1 нче кушымта

2023-2025 елларга Алабуга муниципаль районында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаның кыска сроклы планын үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең исеме | Күпфатирлы йортларның гомуми мәйданы, барлыгы | Программаны раслау датасына күпфатирлы йортларда теркәлгән халык саны | Күпфатирлы йортларда саны | | | | | Капиталь ремонт бәясе, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | Барлыгы: | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | Барлыгы: |
| | | кв. м. | | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 2023 - 2025 елларда барлыгы | | 367,531.79 | 13,852.00 | | | | 64.00 | 64.00 | | | | 431,164,578.88 | 431,164,578.88 |
| 2023 ел | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Алабуга районы | 127,785.07 | 4,819.00 | | | | 20.00 | 20.00 | | | | 153,440,291.21 | 153440291.2 |
| 2024 ел | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Алабуга районы | 100,205.89 | 3,680.00 | | | | 21.00 | 21.00 | | | | 158,523,275.00 | 158523275 |
| 2025 ел | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Алабуга районы | 139,540.83 | 5,353.00 | | | | 23.00 | 23.00 | | | | 119,201,012.67 | 119201012.7 |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 2021 от 14.12.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 14.12.2023 13:24

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>14.12.2023 - 13:27 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН